**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422635 Лаишевский район,
село Атабаево,ул.Молодежная , д.1
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)4-87-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422635 Лаеш районы, Атабай авылы
ул.Яшьлэр урамы, 1нче йорт
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)-4-87-41

**2020 елның 16 апреле** **40 номер**

# КАРАР

**2020 елда Атабай авыл җирлеге бюджеты**
**үтәлеше турындагы хисап буенча гавами**
**тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2014 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Атабай авыл җирлеге Советы Уставының 19 статьясы нигезендә, Атабай авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Атабай авыл җирлеге Советы карарлары проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, Атабай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Атабай авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап буенча халык тыңлауларын 2021 елның «23» апреленә 14.00 сәгатьтә Атабай мәдәният йорты бинасында билгеләргә.
2. 2020 елда Атабай авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы хисап буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә, «22» апрельгә кадәр, түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Атабай авылы, Яшьләр урамы, 1 йорт яисә факс буенча- 884378-4-87-41.
3. Җирлекнең Башкарма комитетына 2020 елда Атабай авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисап буенча гражданнарның гавами тыңлауларын үткәрүне, тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны Атабай авыл җирлеге бюджетының 2020 елда үтәлеше турында хисап белән Атабай авылы, Яшьләр урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендта игълан итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.Р.Хәлилова**